СИШӘМБЕ
16
МАРТ
1943 ел.
№ 60 (6782)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӘЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ЯРДӘМЧЕ ХУҖАЛЫКЛАР ЯЗГЫ ЧӘЧҮ АЛДЫННАН

Үрнәк төстә эшләүче, үз кырларыннан югары уңыш алучы ярдәмче хуҗалыклар турыдан-туры фронтка ярдәм итәләр. Алар, бер яктан—героик Кызыл Армиябез өчен корал коючы эшчеләр массасын азык продуктлары белән тәэмин итү эшен тагын да яхшырталар һәм икенче яктан—дәүләттән план нигезендә алынырга тиешле булган продуктларны фронтка, батыр сугышчыларыбызга җибәрү мөмкинлеген бирәләр. Димәк, үзеннән-үз аңлашыла: предприятиеләр һәм учреждениеләр каршындагы ярдәмче хуҗалыклар сугыш шартларында чиксез зур әһәмияткә ия булып торалар.

Дөресен генә әйтергә кирәк, үткән елны күп кенә ярдәмче хуҗалыклар үз бурычларын сугыш чорына лаеклы рәвештә үти алмадылар. Безнең ярдәмче хуҗалыкларыбыздагы төп кимчелекләрнең берсе—уңышның түбән булуында. Моның сәбәпләре бик ачык: чәчү соңга калып үткәрелде, җир яхшылап эшкәртелмәде, агротехника чаралары тиешенчә үткәрелмәде, игеннәр әйбәтләп тәрбияләнмәде һ. б.

Ярдәмче хуҗалыкларда быелгы язгы чәчү башланугa күп вакыт калмады. Хәзер сугышчан бурыч—үткән елгы ялгышларны, кимчелекләрне һич тә кабатламыйча, язгы чәчүгә тәмам әзерлекне бик тиз тәгаллау һәм аны үрнәк төстә үз вакытында үткәрүдән гыйбарәт.

Барлык җаваплылыкны тулы килеш аңлап, эшне чын-чынлап большевикларча оештырган урыннарда язгы чәчүгә әзерлек яхшы алып барыла. Менә, мәсәлән, баш инженеры иптәш Горбачев булган завод бу яктан күпләргә үрнәк булып тора ала. Завод һәм ОРС җитәкчелеге (ОРС начальнигы Жуков, совхоз директоры Никифоров) үз хуҗалыкларында язгы чәчүне отлично үткәрү һәм быел хәрби югары уңыш алу өчен бик күп практик чараларны үз вакытында һәм эшлекле рәвештә үткәреп баралар. Хәзер заводның совхозы язгы чәчүгә тулысынча әзерләнгән дияргә мөмкин. Кирәкле булган барлык орлыклар әзерләнеп, чистартылып куелган. Машиналарга, инвентарьларга ремонт ясау эшләре төгәлләнгән. Язгы кыр эшләрен тарту көчләре белән тәэмин итү буенча монда яхшы инициатива күрсәтәләр. Булган тарту көчләренә өстәмә рәвештә 6 үгез һәм сыер җигүлe эшкә өйрәтелде. Төрле сбруйлар эшләү һәм ремонтлау мастерскоe оештырылды. Завод ОРС ы каршында 18 кешелек тракторчылар курсы эшли һ. б. ОРС начальниклары Измайлов, Машкович һ. б. булган заводларда да шулай ук язгы чәчүгә әзерлек эшләре нигездә төгәлләнгән дияргә мөмкин.

Ләкин, вакытның бик аз калуына да карамастан, һаман да әле акрын кыймылдаучы, узган елгы ачы сабакларны онытучы җитәкчеләр дә бездә аз түгел әле.

Баш инженеры иптәш Кадышев булган завод, мәсәлән, үз ярдәмче хуҗалыгында язгы чәчүгә әзерлекне төгәлләү буенча җитәрлек энергия белән эшләми. Чәчүлек орлык әлегә кадәр әзерләнмәгән. Бу эш өчен билгеләнгән вәкилләр бик соң гына эшкә керешкәннәр һәм алар кайдан, ничек, кайчан, никадәр һәм нинди сыйфатлы чәчү орлыгы табып алып кайтырлар—билгесез. Яшелчә орлыклары да бик аз гына әзерләнгән. Мәсәлән, кыяр, суган, кишер, помидор кебек культуралар өчен әзерләнгән орлык нибары 10—20 процент. Мондый мисалларны бутән кайбер предприятиеләрдән дә китерергә мөмкин. Җитәкчеләр моның шикелле зарарлы гамьсезлектән, борыла алмаучылыктан ваз кичәргә һәм үзләрен ил алдында, фронт алдында тирән җаваплы итеп сизәргә тишеләр.

ОРС—заводның иң мөһим цехларыннан берсе итеп каралырга тиеш. ОРС ларның, ярдәмче хуҗалыкларның эшләре завод җитәкчелегенең, партия, комсомол, профсоюз оешмаларының игътибар үзәгендә булсын. ОРС ның, ярдәмче хуҗалыкның эше өчен җавап бирү—производство планнарының үтәлеше өчен җавап бирү белән бер тигез җитди булырга тиеш. Мәсьәләне бары тик шулай куйганда гына без ярдәмче хуҗалыкларда язгы чәчүне үз вакытында, үрнәк төстә үткәрә алырбыз һәм быел, сугыш вакыты таләп иткәнчә, югары хәрби уңыш җыеп ала алырбыз.



Төньяк флот. Рәсемдә: су асты көймәсе сугыш походында. Вахтада (сулда) орденлы А. М. Жуков. орденлы электрик Г. Н. Ширяев һәм ТАСС фотохроникасы.

Совет Информбюросыннан

14 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

14 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

Вязьмадан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Халык яши торган бер пункт районында немецларның бер батальон пехотасы, танклар ярдәме белән, бер төн эчендә ике тапкыр контратака ясады. Безнең сугышчылар дошманны алып ташладылар һәм, аны куып барып, халык яши торган пунктны алдылар. Немецларның 4 танкысы сафтан чыгарылды һәм 200 гә якын гитлерчы юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында төрле сугыш милекләре төялгән 40 повозка бар. Вязьмадан көньяктарак безнең частьлар халык яши торган 20 гә якын пунктны һәм тимер юл станциясе Милятинский заводны алдылар.

* * *

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең гаскәрләр алга таба бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть сугышчылары дошманның бер терәк пунктын чолгап алдылар һәм корал ташлаудан баш тарткан бер ротадан артык гитлерчыларны кырдылар. Танкка каршы ата торган 3 орудие. 5 миномет, 9 пулемет, бер запас частьлар склады, авторемонт мастерскойлары һәм берничә штабель артиллерия снарядлары кулга төшерелде.

* * *

Харьков районында безнең частьлар сугышлар алып бардылар. Сугышлар торган саен катырак характер ала баралар. Совет сугышчылары сан ягыннан өстен булган дошман танкларының һәм мотопехотасының атакаларын батырларча кире кайтаралар. Бер участокта гитлерчылар безнең оборонабызга үтеп кера алганнар иде. Н-че часть сугышчылары, контратакага күчеп, дошманны алып ташладылар. Сугыш кырында немецларның сафтан чыгарылган 9 танкысы 3 бронемашинасы, 2 самоход орудиесе, 12 минометы һәм 500 гә якын гитлерчыларның үле гәүдәләре калды. Н-че часть артиллеристлары дошманның һөҗүм итеп килүче танкларына һәм пехотасына каршы көчле ут алып бардылар. Немецларның 7 танкысы зарарланды һәм яндырылды, бер батальонга якын пехотасы таркатылды һәм бер өлеше юк ителде.

* * *

Ровно өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары шоссе юлында засада оештырганнар һәм, гранаталар ыргытып, немецларның 19 автомашинасын юк иткәннәр. 80 гә якын гитлерчы һәм, шул исәптән, берничә офицер үтерелгән. Икенче бер отрядның бер группа партизаннары немецлар полициясе отрядына һөҗүм иткәннәр һәм бер кул пулеметы, 19 винтовка, күп кенә патроннар кулга төшергәннәр.

* * *

Немец-фашист кабахәтләр Ростов өлкәсендәге Больше-Крепинская станицасын җимереп бетергәннәр. Немецлар станицадагы 1.200 йорттан 840 йортны яндырганнар. 4.000 кеше йортсыз-җирсез калган. Гитлерчы бандитлар станицада кино-театрны, клубны, ике мәктәпне, почтаны, универмагны, электр станциясен һәм радиоузелны юк иткәннәр. Җимерүләр коточкыч ерткычлыклар белән һәм гражданнар халкын үтерүләр белән барган. Чигенгән чакта гитлерчылар колхозчыларны талаганнар һәм 15 яшьтән 50 яшькә кадәр булган барлык ирләрне үзләре белән алып китәргә маташканнар. Кызыл Армиянең тиз һөҗүм итүе нәтиҗәсендә генә станица халкы немецлар каторгасыннан котылып кала алды.

* * *

Тронхейм шәһәрендә Норвегия патриотлары немецлар пароходына бомба ташлаганнар. Шартлау нәтиҗәсендә күп гитлерчылар үлгән һәм яраланган. Ставангер районында бер группа коралды норвегияләр бер хәрби складка һөҗүм иткәннәр. Норвегиялеләр, немец сакчыларны үтереп, склад биналарына ут төрткәннәр. Немец оккупантларның күп снарядлары һәм төрле сугыш милекләре утта янып беткән.

14 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

14 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

7 нче марттан 13 енә кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 260 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 110 самолет югалттык.

* * *

13 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 артиллерия һәм миномет батареясының утын бастырдылар һәм 8 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Вязьмадан төньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Холм-Жирковский районында немецлар бик күп пехота һәм 20 гә якын артиллерия батареясы тупладылар. Совет частьлары, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, Днепр елгасы аркылы чыктылар һәм гитлерчыларны елганың көнбатыш ярындагы күп кенә терәк пунктлардан бәреп чыгардылар. Сугыш кырында дошманның йөзләрчә үле гәүдәләре калды. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Безнең башка частьларыбыз, киң фронт булып, Вязьма елгасын аркылы кичтеләр. Вязьма шәһәреннән көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга киттеләр һәм халык яши торган дистәләрчә пунктларны алдылар.

* * *

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган 30 пунктны алдылар. Безнең подразделениеләр алган, халык яши торган бер пунктның урамнарында дошманның 300 дән артык үле гәүдәләре табылды. 6 орудие, танкка каршы ата торган 7 мылтык, күп кенә пулеметлар, винтовкалар, бер сугыш припаслары складны һәм төрле сугыш милекләре тутырылган тагын бер склад кулга төшерелде.

* * *

Харьков районында бик каты сугышлар дәвам итте. Безнең артиллериябез һәм бронебойщикларыбыз уты белән дошманның берничә дистә танкысы һәм пехота төялгән 60 тан артык автомашинасы юк ителде. Харьковтан төньяктарак безнең частьлар дошман пехотасына һәм танкларына каршы киеренке сугышлар алып бардылар. Бу сугышлар барышында немецларга гаять зур зыян китерелде.

* * *

Изюм районында Н-че берләшмә сугышчылары ике көн эчендә немецларның 16 танкысын, 2 бронемашинасын яндырдылар һәм сафтан чыгардылар, бер батальоннан артык гитлерчыларны юк иттеләр. Икенче бер участокта дошман атакага 11 танк һәм зур гына автоматчиклар группасы җибәрде. Командиры иптәш Паршак булган зенит батареясының артиллеристлары ут ачтылар. Немецлар, 5 танкларын югалтканнан соң, ашыгыч рәвештә чигенделәр.

* * *

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары шушы көннәрдә зур тимер юл күперен шартлатканнар. Фронтка бара торган бу бик әһәмиятле юлда поездлар йөреше тукталган. Күперне шартлату операциясе вакытында 140 немец солдаты һәм офицеры үтерелгән. Орел партизаннарының икенче бер отряды дошманның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Паровоз җимерелгән. Немец солдатлары һәм офицерлары утырган 6 вагон юк ителгән.

* * *

Немецларның 320 нче пехота дивизиясенең 585 нче полкының штаб ротасыннан үзе теләп пленга бирелгән солдат Генрих П. болай диде: «Безнең полк Франциядә иде. Ул, Шербурдан көньяктарак, 40—50 километр киңлектә оборона линиясе алып тора иде. Бу участокта ныгытмалар тимерчыбык белән әйләндереп алынган ДЗОТ лардан тора иде. ДЗОТ ларның аралары 2—3 километр итеп калдырылган иде. Һәрбер ДЗОТ гарнизонында 30 ар кеше һәм 2 шәр станоклы пулемет бар иде. ДЗОТ лар арасындагы яр буен бары тик патрульләр генә саклап тора иде. Хәзер инде немецларның Франциядәге күп дивизияләре көнчыгыш фронтка җибәрелгәч, Франциядә калган частьларның саны бик аз, алар көчсезләр һәм зур десантларга каршы көрәшерлек түгелләр».

* * *

13 нче мартта Берлин радиосы: «Германия гаскәрләре Вязьмадан чигенгән чакта тарихи яктан кыйммәтле булган барлык әйберләрне шәһәрдән алып киттеләр»,—дип хәбәр итте. Берлин радиосының бу хәбәрендә бераз дөреслек бар. Бу дөреслек, гитлерчыларның, Кызыл Армия ударлары астында чигенгән чакта, Вязьманы талаган булуларыннан гыйбарәт. Ләкин каракның бөтен дөреслекне сөйләп бирә торган гадәте юк. Чынлыкта фашист бандитлар тарихи яктан кыйммәтле әйберләрне урлау белән генә калмадылар. Гитлерчылар, шәһәрдәге җәмәгать һәм культура учреждениеләренең милекләрен урлаганлыкларын һәм халыкның барлык квартираларын талап чыкканлыкларын әйтми калдыралар.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы

Промышленностьның, авыл хуҗалыгының, фәннең, техниканың һәм сәнгатьнең алдынгы хатын-кызларын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләү турында

(ДӘВАМЫ)

Халыкара коммунистик хатын-кызлар көне—8 нче мартны истә калдыру теләге белән промышленностьның, авыл хуҗалыгының, фәннең, техниканың һәм сәнгатьнең алдынгы хатын-кызларыннан түбәндәгеләрне Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләргә:

147. Екатерина Захаровна **Косовскаяны**—Н-че завод эшчесе.

148. Ирина Сергеевна **Костинаны** — Казан шәһәренең 1 нче номерлы икмәк заводының өлкән мастеры.

149. Мария Николаевна **Котованы** — Н-че заводта ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсоргы.

150. Пелагея Яковлевна **Кочинаны** — СССР Фәннәр Академиясе физика-математика фәннәре докторы.

151. Мария Матвеевна **Кузнецованы**—Куйбышев исемендәге завод эшчесе.

152. Анастасия Алексеевна **Кузьминаны**—Чистайдагы мебель фабрикасы мастеры.

153. Анастасия Ивановна **Кузьминаны**—Казандагы автогараж җиһазлары заводының токаре.

154. Пелагея Васильевна **Куликованы**—Бондюг заводы эшчесе.

155. Евдокия Васильевна **Купчикованы**—шәһәрнең 21 нче номерлы почта бүлеге почтальоны.

156. Мария Яковлевна **Курашны**—Казан тимер юлы Юдино депосының машинисты.

157. Мария Маркеловна **Кускованы** — Н-че завод эшчесе.

158. Наталия Ивановна **Лаврентьеваны**—Казан җитен комбинаты тукучысы.

159. Надежда Владимировна **Ланскаяны**—Молотов районы мәгариф бүлеге мөдире.

160. Сара **Латыйпованы**—Казан станциясенең ягулык складың эшчесе.

161. Лидия Алексеевна **Леденцованы** — ТАССР Наркомземының финанс бүлеге начальнигы урынбасары.

162. Анастасия Михайловна **Ледневаны**—Н-че завод эшчесе.

163. Анна Ивановна **Леликованы**—Н-че төзү тресты мастеры.

164. Анна Антоновна **Липаниннаны**—Казмехкомбинат бригадиры.

165. Татьяна Степановна **Лобашеваны** — Казан тимер юлы стрелкачысы.

166. Анна Ивановна **Лощилинаны**—Чистайдагы мебель фабрикасы эшчесе.

167. Александра Никифоровна **Лыбинаны**—эвакогоспитальнең политик эшләр буенча начальник урынбасары.

168. Анна Пантелеевна **Макаренконы**—Н-че завод эшчесе.

169. Надежда Михайловна **Маловапы** — Н-че заводның завком председателе.

170. Мария Александровна **Малючеваны**—Н-че завод эшчесе.

171. Рәисә Закирҗан кызы **Мансурованы**—Н-че завод эшчесе.

172. Агафья Александровна **Маркованы**—ВКП(б) ның Казан шәһәре, Киров райкомының кадрлар буенча секретаре.

173. Лидия Григорьевна **Макарованы** — фәнни сотрудник.

174. Вера Николаевна **Медведеваны** — Казан тимер юлы электромеханигы.

175. Мария Давыдовна **Мейзлерны** — ВКП(б) ның Казан шәһәр комитетының промышленность бүлеге мөдире.

176. Сара Рувимовна **Межвинскаяны** — заводның цех начальнигы урынбасары

177. Наталия Ивановна **Мещерякованы**—Казан леспромхозының урман кисүчесе.

178. Миңсылу **Миңлемуллинаны**—Кукмара районы, Сталин исемендәге колхозның бозау караучысы.

179. Раиса Михайловна **Минковичны** — Н-че заводның техник бүлегенең группа җитәкчесе.

180. Анастасия Ивановна **Миронованы**—Чистайдагы «Красная звезда» такта заводы эшчесе.

181. Таифә Шиһап кызы **Мифтахованы**—Н-че завод токаре.

182. Вера Петровна **Михайлованы** — ТАССР Урман промышленносте наркоматы экономисты.

183. Зинаида Ивановна **Мокееваны**—Н-че заводның башлангыч партоешма секретаре.

184. Анна Михайловна **Мурашеваны** — Биектау МТС ы тракторчысы.

185. Вагыйзә **Мөрсәлимованы**—Казанның 1 нче номерлы тегү фабрикасы эшчесе.

186. Шәмсекамал **Мусинаны**—Алабуга районы, Фрунзе исемендәге колхозның сыер савучысы.

187. Факиһә Якуп кызы **Мөслимованы**—хезмәт ияләре депутатларының Сталин район советы башкарма комитеты председателе урынбасары.

188. Сагура **Мустафинаны**—Кукмара районы, Яңиль МТС ы тракторчысы.

189. Зөләйха Билял кызы **Мөхәмәтҗановны**—ТАССР НКВД сотрудницасы.

190. Анфиса Гарифулла кызы **Мөхәметшинаны**—ВКП(б) ның Казан шәһәре, Ленин райкомының сектор мөдире.

191. Мәхки **Нәгыймованы**—«Пролетарий» такта заводы эшчесе.

192. Мәгъмурә **Нәзированы**—1 нче Май МТС ы тракторчысы.

193. Разия Сәгыйт кызы **Насриеваны** — Казан шәһәренең 1 нче инфекция больницасы санитаркасы.

194. Клавдия Сергеевна **Наумованы** — 1 нче Май районы, Чишмә урта мәктәбе укытучысы.

195. Лидия Николаевна **Невейцеваны**—хәрби часть машинисткасы.

196. Татьяна Васильевна **Нестерованы**—хезмәт ияләре депутатларының Молотов район советы башкарма комитеты председателе урынбасары.

197. Валентина Архиповна **Нигрецкаяны**—Н-че завод эшчесе.

198. Хәдичә Низаметдин кызы **Низаметдиновны**—Казан универмагы сатучысы.

199. Мария Степановна **Никитинаны** — Н-че завод эшчесе.

200. Тамара Николаевна **Никитинаны**—Н-че завод эшчесе.

201. Хөршит **Нургалиеваны** — Кукмара МТС ы тракторчысы.

202. Валентина Ивановна **Одинцованы**—3 нче номерлы тегү фабрикасы эшчесе.

203. Анна Григорьевна **Осиповны**—Казан тимер юлының шәһәр тирәсе станциясе телефонисткасы.

204. Анна Павловна **Павлованы**—Казан шәһәре, ВКП(б) ның Дзержинский райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире.

205. Галина Ефимовна **Певцованы**—Казан шәһәре, ВКП(б) ның Молотов райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире.

206. Мария Моисеевна **Перепелицинаны**—Казан тимер юлының нормалаштыру группасы начальнигы.

207. Анна Осиповна **Петрованы**—Юдино районы, Раиф тулы булмаган урта мәктәп укытучысы.

208. Ольга Ивановна **Петрованы**—Теләче урта мәктәбе укытучысы.

209. Прасковья Матвеевна **Петрованы**—Н-че завод эшчесе.

210. Клавдия Степановна **Петрухинаны**—Вахитов исемендәге жиркомбинат эшчесе.

211. Прасковья Сергеевна **Платонованы**—Ширәмәт районы, «Прикамский» совхозының бозау караучысы.

212. Фрума Ерошеевна **Плисанны**—Н-че завод эшчесе.

213. Тамара Игнатьевна **Пионтковскаяны**—Н-че заводның цех профоргы.

214. Екатерина Ивановна **Попованы** — Н-че завод эшчесе.

215. Александра Филипповна **Постнованы**—ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының кадрлар бүлеге мөдире урынбасары.

216. Наталия Васильевна **Прокопованы**—Н-че азвод эшчесе.

217. Агриппина Андреевна **Просвирнованы**—«Спартак» комбинаты эшчесе.

218. Анна Ивановна **Пьянкованы**—Н-че завод ОРС ының 4 нче номерлы ашханәсе мөдире.

219. Җәүһәрия Габдерахман кызы **Рафикованы**—«Спартак» комбинатының электр монтеры.

220. Миңлеҗамал **Рәхимованы**—Алексеевский районы, «Красный Восток» колхозының бозау караучысы.

221. Рәисә Низами кызы **Рахманкулованы**—Н-че завод эшчесе.

222. Миңлегөл **Рахматуллинаны**—Алексеевский районы, Ворошилов исемендәге колхозның бозау караучысы.

223. Агафья Степановна **Резцованы** — Мамадыш районы, «Агробаза» совхозының дуңгыз караучысы.

224. Прасковья Андреевна **Рогованы** — Н-че завод эшчесе.

225. Александра Ивановна **Романинаны**—Н-че завод эшчесе.

226. Антонина Афанасьевна **Рубанны** — эвакогоспитальнең өлкән медсестрасы.

227. Мария Григорьевна **Румянцеваны**—Н-че завод эшчесе.

228. Людмила Митрофановна **Русскихны**—Казан шәһәренең 25 нче номерлы урта мәктәбе директоры.

229. Сәкинә **Сабированы**—Арча районы, Казанбаш МТС ы тракторчысы.

230. Рәисә Сабирҗан кызы **Сабирҗанованы**—Югары Ослан районы, Куралы промсовхозының звено башлыгы.

231. Сәидә **Сабирҗанованы**—Н-че төзү тресты эшчесе.

232 Екатерина Степановна **Саврасованы**—1 нче номерлы ТЭЦ эшчесе.

233. Ситдика **Сәгыйтованы**—Таткоопинсоюзның «Иншвейпром» артеле эшчесе

234. Разия Фәйзерахман кызы **Садыйкованы**—Казан пристане эшчесе.

235. Нәсимә **Салихованы**—Н-че завод эшчесе.

236. Гатифә **Салахиеваны**—Кукмара МТС ы тракторчысы.

237. Разия Сәмигулла кызы **Сәмигуллинаны**—Татполиграф типографиясенең хәреф җыючысы.

238. Елена Львовна **Самофалованы** — Н-че завод мастеры.

239. Асия Баһир кызы **Саттарованы** — Н-че завод эшчесе.

240. Хәкимә **Сафиуллинан**—Н-че завод эшчесе.

241. Екатерина Александровна **Сафонованы**—ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты инструкторы.

242. Мәрьям Габдерахман кызы **Сафьяновны**—Н-че завод эшчесе.

243. Рәхимә Сахап кызы **Сахапованы** — Тымытык районы, Чалпы МТС ы комбайнчысы.

244. Мария Лукьяновна **Семакованы** — «Азат хатын» промартеленең председателе.

245. Анна Павловна **Семеновны** — Алексеевский районы, «Победа» колхозының сыер савучысы.

246. Татьяна Ивановна **Служаеваны**—Тельман районы, «МЮД» совхозы комбайнчысы.

247. Наталия Ивановна **Соколованы** — «Урак һәм чүкеч» заводы эшчесе.

248. Полина Тимофеевна **Соловейны** — Н-че заводның РОКК председателе.

249. Елена Федоровна **Соловьеваны** — ВКП(б) ның Казан шәһәр комитеты инструкторы.

250. Галина Степановна **Соменкованы**—Ясалма күн заводы бригадиры.

251. Серафима Михайловна **Старателеваны**—Н-че завод эшчесе.

252. Евгения Ивановна **Стариковны** — Н-че завод эшчесе.

253. Нина Алексеевна **Старшиновны** — Казан автогаражлар җиһазы заводы токаре.

254. Александра Алексеевна **Степанованы**—Н-че завод эшчесе.

255. Татьяна Максимовна **Степанованы**—Н-че төзү тресты эшчесе.

256. Ольга Алексеевна **Стецкаяны** — СССР Фәннәр Академиясенең физик проблемалар институты директоры урынбасары.

257. Мария Ивановна **Столбованы**—Казан шәһәре, Киров районындагы 2 нче номерлы балалар консультациясе мөдире.

258. Миңлекамал **Сөләйманованы** —Н-че завод эшчесе.

259. Фәхриҗиһан Габдерахман кызы **Таҗетдинованы**—Казан үзәк телеграфы эшчесе.

260. Лидия Петровна **Танкееваны** — Туку фабрикасы эшчесе.

261. Мария Тимофеевна **Тарасованы**—Н-че завод лаборанткасы.

262. Прасковья Владимировна **Тимофееваны**—Куйбышев районы, «КИМ» совхозы бозау караучысы.

263. Наталья Степановна **Товманы**—Вахитов исемендәге жиркомбинат механигы.

264. Евгения Константиновна **Торопецны**—Казан үзәк телеграфы эшчесе.

265. Роза Хәкимҗан кызы **Усманованы**—ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитетының крестьян яшьләре бүлеге мөдире.

266. Фирдәвес Йосыф кызы **Уразованы**—Казан химия-технология институтының өлкән укытучысы.

267. Фәхериса **Фәйхетдинованы**—Бондюг заводы эшчесе.

268. Җиһан Сабир кызы **Фатихованы**—Казан шәһәре он заводының производство мөдире.

269. Мөнирә **Фатихованы**—«Пролетарий» такта заводы эшчесе.

270. Галия **Фәхриеваны**—Кайбыч районы, Мөрәле МТС ы тракторчысы.

271. Татьяна Владимировна **Фединаны**—Казан шәһәр телефон станциясенең телефонисткасы.

272. Евдокия Федоровна **Федорованы** — Кукмара районы, Яңиль МТС ының трактор бригадасы бригадиры.

273. Ольга Ивановна **Федорованы** — Н-че завод эшчесе.

(Дәвамы бар).



Рәсемдә: Казан фармзаводы эшчесе иптәш К. Воробьева. Ул Май алды ярышында алган йөкләмәсен 200 процент итеп үтәп бара.

К. Тахтеев фотосы.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

БАШ КОМАНДОВАНИЕ ФОНДЫНА

Баш инженеры иптәш Корнеев булган Н-че завод дирекциясенең партия, комсомол, профсоюз активы катнашы белән берлектә киңәйтелгән утырышы булды. Утырышта ике орденлы 92 нче завод коллективының 1 нче Май алды социалистик ярышын оештыру турындагы мөрәҗәгате тикшерелде, завод директорының март һәм апрель айларында алда торган бурычлар турындагы доклады тыңланды.

Докладтан соң чыгып сөйләүчеләр май ярышына кушылачакларын белдерделәр һәм конкрет йөкләмәләрен әйттеләр. Стахановчы цехның начальнигы иптәш Андреев 1 нче Май хөрмәтенә стахановчы вахтага басарга завод җитәкчелегенең рөхсәт биргүен сорады. Ул бөтен цех коллективы исеменнән эшләп чыгаруны тагын да күтәрергә, Кызыл Армиянең Верховный Баш Командованиесе фондына өстәмә рәвештә күп кенә продукция бирергә йөкләмә алды.

Башка цехларның начальниклары да иптәш Андреев җитәкчелегендәге коллективның инициативасын якладылар һәм стахановчы вахтага басарга сүз бирделәр.

Актив завод коллективының 1 нче Май алды социалистик ярыш йөкләмәсен кабул итте. Бу йөкләмәдә март һәм апрель планнарын 10 процентка арттырып үтәргә, рационаллаштыру тәкъдимнәрен тормышка ашыру белән дәүләткә кимендә 3 миллион сумлык файда бирергә, электр энергиясенә һәм ягулыкка экономия ясарга, Кызыл Армиянең Верховный Баш Командованиесе фондына уннарча өстәмә изделие эшләп чыгарырга дигән пунктлар бар.

КӨНГӘ ИКЕШӘР-ӨЧӘР НОРМА

«Промполиграф» артеле коллективы, Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә оештырылган ярышка йомгак ясап, 1 нче Май алды социалистик ярышына чыкты. Тартма цехы белән төпләү цехы үзара ярыш договоры төзеделәр. Алар март һәм апрель айларында планны 10 процентка арттырып үтәргә, эш көченнән, материаллардан, ягулыктан һәм электр энергиясеннән рациональ төстә файдаланырга, яшь эшчеләрне квалификациягә өйрәтү өлкәсендә эшне көчәйтергә дип йөкләмә алдылар.

Начальнигы иптәш Верниковский булган басу цехы ярышта алда бара. Бу цех коллективы мартның беренче ун көнлек планын 130 процентка үтәде. Цехтагы барлык эшчеләр дә көнлек норманы үтәп һәм арттырып үтәп баралар. Фәтхуллина, Кузнецова һәм Медведева кебек стахановчылар көненә 1,5—2, ә кайбер вакытларда 3 әр норма биреп эшлиләр.

БАЙРАК ТАПШЫРЫЛДЫ

Баш энергетигы иптәш Андреев булган Н-че завод ягулыкка, җылылык һәм электр энергиясенә экономия ясау буенча Казан шәһәре предприятиеләре арасында оештырылган социалистик ярышта беренче урынны алган иде. Шушы көннәрдә завод коллективына ВКП(б) шәһәр комитетының күчмә Кызыл Байрагы һәм грамота тапшырылды. Байракны һәм грамотаны кабул иткәндә баш энергетика коллективы җылылык һәм электр энергиясенә экономия ясау буенча март һәм апрель айларында тагын да зуррак уңышларга ирешергә, Кызыл Байракны үз кулларында сакларга сүз бирде.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

Колхозчылар үз колхозларына ярдәм итәләр

Кызыл йолдыз, Беренче Май районнарының алдынгы колхозчылары, үз колхозларына чәчү орлыгы белән ярдәм итүне оештырып, бөек патриотизм үрнәге күрсәтәләр. Алдынгыларның гүзәл башлангычын киң җәелдерик! Колхозларны чәчү орлыгы белән тәэмин итүдәге бөтен мөмкинлекләрдән файдаланыйк!

Патриотик эш

ЧИРМЕШӘН, 15 март. (Телефон буенча). Орлыклары җитешми торган колхозларга булышлык тәртибендә колхозчылар бурычка орлык бирәләр. Шул тәртиптә район буенча 755 центнер бөртекле ашлык, 1.380 центнер бәрәңге, 33 килограмм яшелчә орлыгы тупланды инде.

Куйбышев исемендәге колхоз члены иптәш М. Фомин 6 центнер бөртекле ашлык, 3 центнер бәрәңге, иптәш Колотушкин 3 центнер бөртекле ашлык, бер центнер бәрәңге орлыгы, Декина Ольга 5 центнер бөртекле ашлык бирделәр. «Бүләк» колхозы членнары да бу әһәмиятле чараны тормышка ашыруда актив катнашалар. Мотыйгулла иптәш Галиев үз колхозына 3 центнер бөртекле ашлык, бер центнер бәрәңге, иптәш Талипов 2 центнер бөртекле ашлык, бер центнер бәрәңге бирделәр.

Районыбызның 63 колхозыннан 11 колхоз үзләренә кирәкле чәчүлек орлыкларны барлык культуралар буенча да әзерләп бетерделәр. Ләкин бу өлкәдә алда шактый күп эш тора әле.

Ш. ГАЗИЗУЛЛИН,
ВКП(б) ның Беренче Май райкомы секретаре.

* * *

КУЗНЕЧИХА, 15 март. (Телефон буенча). Колхозларны чәчү орлыклары белән тәэмин итү буенча колхозчылар бик яхшы патриотик үрнәк күрсәтәләр. Алар колхозларга чәчү орлыклары биреп торалар. Дөрес, бездә бу эш башланды гына әле. Шулай да беренче нәтиҗәләр бар. Бүгенге көнгә колхозчылардан 1.400 центнер бәрәңге орлыгы керде. Шулай ук бөртекле ашлык орлыкларын туплау да җанланып килә. «Красный флот» колхозы членнары үз колхозларына 4 центнер, «Новая жизнь» колхозы членнары 14 центнер, «Красная Поляна» колхозы членнары 6 центнер бөртекле ашлык орлыгы бирделәр. «Роза» колхозы членнары шул тәртиптә 120 центнер бәрәңге, «Кызыл Октябрь» колхозы членнары 80 центнер бәрәңге тупладылар.

ЧЕРНЫШЕВ,
ВКП(б) ның Кузнечиха райкомы секретаре.

БӘРӘҢГЕ КИСЕНТЕЛӘРЕ ӘЗЕРЛӘҮ

Биектау районының күп кенә колхозларында быел бәрәңге кисентеләре әзерләүгә колхозчылар нык әһәмият бирәләр. Мәсәлән, Чкалов исемендәге колхоз членнары 25 пот, «Дружба» колхозы членнары 18 пот, Калинин исемендәге колхоз членнары 12 пот әзерләделәр инде. Кисентеләрнең саклануы яхшы.

С. ДИМИТРОВ.

КОЛХОЗЧЫЛАР БУЛЫШЛЫГЫ БЕЛӘН

КОТЛЫ БӨКӘШ, 15 март. (Телефон буенча). Районыбызда чәчү орлыкларын туплау эше көннән-көн кызу темп ала бара. Язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы башлангач орлык туплау сизелерлек дәрәҗәдә яхшырды. Башкача булуы да мөмкин түгел.

Без чәчү орлыклары җитәрлек булмаган колхозларда орлыкны колхозчылардан бурычка алып тору мәсьәләсен куйдык. Колхозчылар бу чараны бик урынлы дип таптылар һәм колхозларга үз хуҗалыкларындагы запасларлан орлыкка ашлык, бәрәңге һәм яшелчә орлыклары бирә башладылар.

Кулда булган мәгълуматларга караганда, без хәзергә кадәр колхозчылардан барлыгы 4.248 пот бөртекле ашлык һәм 37.092 пот бәрәңге орлыгы, 2 центнер кәбестә орлыгы, 2 центнер 42 килограмм суган орлыгы, 4 килограмм чөгендер туплаганбыз. Шулардан 1.092 пот бөртекле ашлык орлыклары, 4.026 пот бәрәңге орлыгы колхоз амбарларына тапшырылды инде.

Карл Маркс исемендәге колхоз членнарының бу чараны үткәрүдә аеруча якыннан торып катнашуларын әйтергә кирәк. Алар колхозга үз хуҗалыкларындагы запастан чәчү орлыгына дип 125 центнер бодай, солы һәм 500 центнер бәрәңге бирделәр. Шулай ук «Авангард» колхозы членнары да 80 центнер бөртекле ашлык, 107 центнер бәрәңге орлыгы тупладылар. «Авангард» колхозы члены иптәш А. Бикташева 5 центнер бөртекле ашлык орлыгы, 2 центнер бәрәңге бирде. «Восход» колхозы членнарыннан Петр иптәш Такранов 10 центнер бөртекле ашлык, 8 центнер бәрәңге, Егор иптәш Такранов 5 центнер бөртекле ашлык һәм 4 центнер бәрәңге орлыгы бирделәр. «Правда» колхозы членнары да колхозга ярдәм итәләр. Колхоз члены Мария иптәш Макашова 5 центнер орлык, 5 центнер бәрәңге бирә. Калинин исемендәге колхоз члены 60 яшьлек Җәмил иптәш Әхтәмҗанов 4 центнер бөртекле ашлык һәм 3,5 центнер бәрәңге бирде.

Х. ХӘЙБУЛЛИН,
ВКП(б) ның Кызыл йолдыз райкомы. секретаре.

ЧӘЧҮ ОРЛЫКЛАРЫН ӘРӘМ-ШӘРӘМ ИТМӘСКӘ

КАЙБЫЧ, 15 март. (Телефон буенча). Язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгының ун көне үтте инде. Ә биредә бу айлыкка кушылу һәм язгы чәчүгә әзерлекне тизләтү турында уйлап та карамаучы колхоз җитәкчеләре бар. Менә «Красная Нива» колхозы. Бу колхозда авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау түгел, хәтта машиналарның кайда икәнлеген һәм аларга нинди ремонт кирәк булуын да ачык белүче юк. Кайбер машиналар кар астында яталар. Чәчүлек орлык та җитәрлек түгел. Шулай булгач, аның һәр граммын төгәл учетка алырга, орлык туплауны тизрәк төгәлләү өчен кискен чаралар күрелергә тиеш иде. Ә бу колхоз председателе Смелов исә киресенчә эшли, бар кадәр орлыкны да сакламый. Алай гына да түгел, ул үзе чәчү орлыкларын әрәм-шәрәм итә. Мәсәлән, күптән түгел генә ул бер колхозчыга колхозның 12 пот бодай орлыгын биреп, үзенә әйбер алган.

«Ударник», Карл Маркс һәм Ленин исемендәге колхозларда да язгы чәчүгә әзерлек начар бара. Чәчү орлыклары тупланмаган. Юеш орлыкларны киптерү оештырылмаган. Ремонт та әзеклектә.

Г. КУШАЙ.

СОВХОЗЛАР ЯРЫШЫ

ЧИСТАЙ, 15 март. (Телефон буенча). Чистай районының «Кормхоз» совхозы (директоры иптәш Хәмидуллин), 1942 нче елда мул иген уңышы алып, дәүләткә ашлык тапшыруны районда беренче булып 104 процентка үтәде. Хәзер совхоз эшчеләре язгы чәчүгә әзерләнәләр.

4 тракторга капитальный ремонт һәм 3 тракторга агымдагы ремонт ясалды. Чәчкечләр, культиваторлар, тырмалар барысы да төзек. Ремонтта эшләүче тракторчылардан Галкин, Максимов, Лунина һәм Маркилова иптәшләр үзара ярышып эшләп, норманы 140—150 процент үтәп баралар. Чәчүлек орлыклар барлык культуралар буенча да җитәрлек бар. Алар тазартылган. План буенча 200 гектар урынына 325 гектарда кар тотылган. Басуга тирес чыгару, көл һәм кош тизәге җыю планы да арттырып үтәлгән. Язгы чәчүдә файдалану өчен 6 пар сыер җигүле эшкә өйрәтелгән.

Совхоз эшчеләре, «Яңа ил» колхозы членнарының мөрәҗәгатен тикшереп, язгы чәчүдә булган кимчелекләрне 25 нче мартка кадәр бетерергә йөкләмә алдылар, һәм «Стахановец» совхозы коллективын социалистик ярышка чакырдылар.

Рәсемдә: художник Н. Сокольский тарафыннан эшләнгән «Яшәсен Сталинград» исемле яңа рәсем.

И. Папков фотосы.

Кызыларьмеец семьяларына ярдәм

Чистай районында кызыларьмеецларның һәм командирларның семьяларына ярдәм күрсәтү буенча күп кенә чаралар үткәрелә. Аларның материаль-көнкүреш шартлары тикшерелә, мохтаҗ булган семьялар утын, терлек азыгы һәм промтоварлар белән тәэмин ителә.

Быел 708 хуҗалыкның материаль-көнкүреш хәле тикшерелде. 1942 нче елның икенче яртысына һәм 1943 нче елның ике аенда кызыларьмеец семьяларына барлыгы 24.500 сум акчалата ярдәм бирелде. 300 пар киез итек, 603 пар күн аяк киеме, 419 пар белье, 9.020 пар оек, 800 пар бияләй, 1.752 метр мануфактура, 250 килограмм сабын һәм 13.798 килограмм төрле ашамлык продуктлары бирелде. 761 хуҗалык терлек азыклары белән тәэмин ителде.

Ләкин кызыларьмеец семьяларына ярдәм итү һәм аларга бирелә торган пособиеләрне үз вакытында түләү буенча кимчелекләр дә бар әле. Мәсәлән, кызыларьмеец семьяларына түләү өчен 27 нче февральдә Мөслим авыл почта бүлегенә җибәрелгән 20.000 сум пособие акчасы 9 нчы мартка кадәр пособие алучылар кулына өләшенми. Почта бүлеге бу акчаны авыл советы работникларына, МТС ка һәм башка кешеләргә бурычка биреп тора. Мондый фактлар Булдырь, Змеево почта бүлекләрендә дә ачылды. Бу фактларга чик куярга һәм кызыларьмеец семьялары турында кайгыртучанлыкны яхшыртырга кирәк.

Ш. ШАКИРОВ.

МАССА-ОБОРОНА ЭШЕН ЯХШЫРТЫЙК

Ватан сугышы шартларында Осоавиахим оешмаларына элеккегә караганда да зуррак җаваплы бурычлар йөкләнә. Алар ПВХО өлкәсендә, хәрби белгечләр әзерләүдә һәм Осоавиахимның башлангыч оешмаларын ныгытуда тагын да тырышыбрак эшләргә тиешләр.

Татарстанда Осоавиахимның күп кенә оешмалары бу бурычларны хәл итүдә шактый зур уңышларга ирештеләр. Азнакай районының Осоавиахим оешмаларын алыйк. Осоавиахимның район советы председателе иптәш Закирова оборона эшләрен ныгытуда зур активлык күрсәтә. Бу районда халыкны ПВХО га әзерләү планы уңышлы рәвештә үтәлде. Барлык колхозларда Осоавиахимның башлангыч оешмалары төзелде. Осоавиахимчылар хәрби эшкә өйрәнүдә гүзәл үрнәкләр күрсәтәләр. 1942 нче елда Осоавиахим членнарыннан 300 гә якын ворошиловча атучы, хатын-кызлардан 83 укчы әзерләнде, 15 кеше радио-телеграф эшен үзләштерделәр.

Бу районның осоавиахимчыларыннан күп кенә иптәшләр ватан сугышы фронтларында зур батырлыклар күрсәтәләр. Гыйльминур Әхтәмова, Тәгъзимә Гәрәева, Зоя Садыйкова һәм башкалар аеруча геройлыклар күрсәттеләр. Сталинградны саклаган вакытта кыюлык һәм батырлык күрсәткән өчен иптәш Садыйкова «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнде. Азнакай районының осовиахимчылары, иптәш Сталинның рәхмәт белдерүе белән һәм Кызыл Армиянең уңышлы һөҗүме белән рухланган хәлдә, Осоавиахим исемендәге самолетлар эскадрильялары һәм танклар колоннасы төзү фондына 35.000 сум акча туплап керттеләр, Кызыл Армия өчен күп кенә җылы киемнәр, 178 центнер бәрәңге, ит һәм башка продуктлар туплап тапшырдылар.

Казан шәһәренең Киров районындагы Осоавиахим оешмалары да яхшы үрнәкләр күрсәтәләр. 1941 нче елда бу районда Осовиахимның 99 башлангыч оешмасы булып, аларда членнарның саны 7.700 дән бераз гына артыграк иде. Хәзер анда 151 башлангыч оешмада членнарның саны 13.000 нән артты. Осоавиахим район советы йорт хозяйкалары арасында да яхшы гына эшләп килә. Анда үткән елны йорт хозяйкаларыннан 1.100 дән артык кеше Осоавиахимга член итеп кабул ителде, һәм йорт идарәләре янында Осоавиахим оешмаларының саны ике тапкыр артты. Йорт хозяйкалары масса-оборона эшләрен оештыруда зур активлык күрсәтәләр. Осоавиахим активистлары хезмәт кияләре арасында киң күләмдә аңлату эшләре алып баралар. Бер ел эчендә предприятиеләрдә, мәктәпләрдә һәм учреждениеләрдә оборона темаларына 750 дән артык беседа, лекция һәм докладлар үткәрелде. Районда членлык взнослары туплау планы тулысынча үтәлде. Халыкны ПВХО га әзерләү планы да шулай ук төгәлләнде. Кызыл Армия өчен хәрби белгечләр әзерләү уңышлы бара. Төз атучылар, минометчиклар, пулеметчиклар һәм телефонистлар әзерләү заданиеләре арттырып үтәлде. Районның осоавиахимчылары промышленность өчен күп кенә төсле металл җыеп тапшырдылар. Йорт хозяйкалары фронтовикларга бүләкләр җибәрү өчен 2.000 сумнан артык акча тупладылар.

Осовиахимның район советы чын хәрби культура штабына әйләндерелгән. Анда көн саен бик күп хезмәт ияләре килә. Райсовет бинасында ПВХО күргәзмәсе оештырылган, төрле мәсьәләләр буенча белешмәләр бирә торган өстәл эшләп килә.

Осоавиахимның Зеленодольск шәһәр советы председателе иптәш Белов та оборона эшләрен ныгытуда яхшы эшләп килә. Бу оешма масса-оборона эшләрен оештыруда, хезмәт ияләрен ПВХО га әзерләүдә Татарстанда алдынгы оешмаларның берсе булып санала.

Шушындый алдынгылар белән беррәттән Татарстанда Осоавиахимның артта калып баручы оешмалары да бар әле. Чистай, Яңа Чишмә, Кузнечиха, Биектау, Тархан, Алексеевский, Акташ, Биләр һәм Апас районнарында халыкны ПВХО га әзерләү эше шушы көнгә кадәр төгәлләнмәгән. Бу җитешсезлекне кичекмәстән бетерергә, халыкны ПВХО га әзерләү планын якын вакыт эчендә үтәргә кирәк.

Татарстан Осоавиахим Үзәк Советының февральдә булып үткән пленумы масса-оборона эшләрен тагын да яхшырту өчен күп кенә чаралар билгеләде. Моңарчы Осоавиахим оешмалары булмаган барлык предприятиеләрдә, колхозларда, совхозларда, МТС ларда, мәктәпләрдә, югары уку йортларында һәм учреждениеләрдә шушы елның 1 нче маена кадәр башлангыч оешмалар төзелергә һәм аларга член итеп хезмәт ияләренең киң катлавы тартылырга тиеш. Халык арасында агитация-масса эшләрен киң җәелдерергә, оборона темаларында доклад, лекция һәм беседаларны системалы рәвештә үткәрергә, Осоавиахимның башлангыч оешмаларын ныгытырга кирәк.

Татарстанның Осоавиахим членнары илебезнең оборона фондына средстволар туплауны тагын да көчәйтергә тиешләр. Иптәш Сталинның приказы барлык хезмәт ияләре өчен, шул исәптән Осоавиахим членнары өчен дә, сугышчан программа булып тора. Фронтка ярдәм итү өчен һәм явыз дошманны тиздән тармар итү өчен бөтен көчебезне бирик.

Б. БИКИЕВ,
Татарстан АССР Осоавиахим Үзәк Советы председателе.

Совет Информбюросыннан

15 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

15 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

Вязьмадан көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне уңышлы рәвештә җәелдерүне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә дистә пунктны, шул исәптән район үзәге һәм тимер юл станциясе Семлевоны алдылар. Н-че часть сугышчылары немецларның 2 рота пехотасын тар-мар иттеләр. Дошманның кыр орудиеләре батареясы, танкка каршы ата торган 5 пушкасы, 12 пулеметы, 9 минометы, күп снарядлары һәм патроннары безнең кулга төшерелде.

* * *

Белый шәһәреннән көньяктарак дошман, алдан әзерләнгән терәк пунктларына таянып, ныклы каршылык күрсәтә, безнең гаскәрләрнең һөҗүмен тоткарларга маташа. Н-че часть сугышчылары, немецларның ныгытмалар полосасын өзеп һәм уңышны җәелдереп, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу сугышларда гитлерчылар үтерелгән хәлдә генә дә 900 ләп солдат һәм офицерларын югалттылар. Безнең подразделениеләр 10 орудие, 22 пулемет, 5 миномет, 39 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Харьков районында безнең гаскәрләр дошманның зур танк көчләренә һәм мотопехотасына каршы бик каты сугышлар алып бардылар. Н-че часть сугышчылары көн һәм төн буена гитлерчыларның өзлексез атакаларын кире кайтардылар. Танкка каршы орудиеләрнең һәм мылтыкларның уты белән немецларның 6 самоход пушкасы җимертелде һәм 14 танкысы юк ителде. Мылтык һәм пулемет уты белән, шулай ук штык һәм кул сугышларында немецларның 600 дән артык солдат һәм офицерлары кырылды. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр каты сугышлардан соң, дошманга авыр югалтулар китереп, яңа оборона чигенә күчтеләр.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең частьлар дошманга каршы артиллерия һәм миномет атышы алып бардылар. Безнең артиллеристларның һәм минометчикларның уты белән немецларның бер танкысы, 10 автомашинасы, бер тимер юл составы һәм бер ротага якын пехотасы юк ителде. Н-че частьның лейтенант Пархоменко командалыгындагы разведчиклар группасы төнлә белән кинәт дошман окопларына атака ясады. Немецлар батальон байрагын, 2 миномет һәм 5 пулемет ташлап калдырып качтылар.

* * *

Чернигов өлкәсе районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның автомашиналарына ремонт ясала торган мастерскойга һөҗүм иткән. Партизаннар, тышкы сакчылыкны тиз генә юк итеп, мастерской территориясенә бәреп кергәннәр һәм аңа ут төрткәннәр. Мастерской һәм анда булган автомашиналар янып беткән. Шул ук отрядның партизаннары ике көннән соң 4 тимер юл күперен шартлатканнар. Икенче бер отрядның партизаннары немецларның фронтка бара торган хәрби эшелонын юлдан чыгарып аударганнар. 13 класс вагоны һәм бер паровоз юк ителгән. Вагон ватыклары астында калып күп гитлерчылар һәлак булган.

* * *

Калинин өлкәсендә немец басып алучылардан азат ителгән авылларның кешеләре гитлерчы бандитларның кыргый ерткычлыклары турында сөйләделәр. Станы авылында немецлар колхозчыларның күп кенә йортларыннан ат сарайлары ясаганнар. Гитлерчылар бер ишек алдына картлардан, хатын-кызлардан һәм балалардан 180 кешене куып кертәннәр һәм аларны кулга алынучылар белән бер дәрәҗәдә тотканнар. Берничә ай эчендә ачлыктан һәм кыйналулардан 67 кеше үлгән. Ситниково авылында немец-фашист кабахәтләр үзләре чигенер алдыннан колхозчы Григорий Петровны, аның хатынын һәм башка кешеләрне атканнар. Бандитлар бик күп яшьләрне Германиягә каторга эшенә куып алып киткәннәр. Бара алмаган барлык кешеләрне гитлерчылар атып үтергәннәр.

* * *

Югославия партизаннары Загребтан көнбатыштарак Италия гаскәрләренең зур бер колоннасын чолгап алганнар һәм тар-мар иткәннәр. «Муссолини» батальоны үтерелгән хәлдә генә дә 450 солдат һәм офицерын югалткан. Партизаннар бик күп трофейлар кулга төшергәннәр. Горни Вакуф-Прозор секторында 8 көнлек сугышлар партизаннарның җиңүе белән тәмам булган. Тар-мар ителгән немец частьлары бик күп коралларын, сугыш припасларын һәм төрле сугыш милекләрен ташлап чигенәләр.

15 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

15 нче мартта безнең гаскәрләр, күп көннәр дәвам иткән бик каты сугышлардан соң, командованиенең приказы буенча Харьков шәһәрен эвакуацияләделәр.

Смоленск өлкәсендә безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам иттереп, Холм-Жирковский шәһәрен алдылар.

Башка фронтларда безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

14 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 9 артиллерия һәм 7 миномет батареясының утын бастырдылар, 8 сугыш припаслары складын шартлаттылар һәм Керчь бугазында 3 катерны һәм 3 баржаны батырдылар.

* * *

Вязьмадан төньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Дошман, Холм-Жирковский районында алдан хәзерләп куелган оборона чигенә таянып, артиллерия уты белән, пехотаның һәм танкларның контратакалары белән безнең гаскәрләрнең һөҗүмен туктатырга маташты. Безнең частьлар, бик каты сугыш нәтиҗәсендә, немецларны бу оборона позицияләреннән бәреп чыгардылар һәм Холм-Жирковский шәһәрен алдылар. Вязьмадан көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдереп, халык яши торган күп пунктларны алдылар. Бик күп немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган 40 пунктны, шул исәптән район үзәге Батуриноны алдылар. Трофейлар кулга төшерелде. Аларның саны алына. Бер участокта дошман контратака ясап караган иде, ләкин алып ташланды һәм сугыш кырында 200 дән артык үле гәүдә калдырды.

* * *

Төньяк Донецның урта агымы районында безнең гаскәрләр дошманга каршы каты сугышлар алып бардылар. Немецлар, уңайлы позицияләргә урнашырга теләп, һөҗүмгә бик күп пехота һәм 18 танк җибәрделәр. Н-че часть подразделениеләре, танкка каршы ата торган орудиеләр уты белән, немецларның сугышчан сафларын таркаттылар һәм 11 танкны юк иттеләр. Гитлерчылар җиргә ятырга һәм окопларга урнашырга маташканнар иде, ләкин безнең сугышчыларның ударлары астында чигенделәр. Сугыш кырында дошманның 300 гә якын үле гәүдәләре калды.

* * *

Ильмень күленнән көньяктарак безнең частьлар немецлар оборонасының көчле итеп ныгытылган бер узелын тар-мар иттеләр һәм бер су чиген кичтеләр. Дошман күп югалтуларга дучар ителде һәм, яралыларны һәм коралларын ташлап, чигенде.

Һава сугышларында безнең очучылар немецларның 8 самолетын бәреп төшерделәр. Шуның өстенә зенит артиллериясе һәм пехота кораллары уты белән дошманның 12 самолеты юк ителде.

* * *

Минск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды бер ай эчендә немецларның 15 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. 9 паровоз һәм 212 вагон җимерелгән. Җимерек вагоннар астында калып бик күп немец солдатлары һәм офицерлары һәлак булган. Тимер юл станцияләренә ясалган һөҗүмнәр вакытында партизаннар автомашиналар төялгән 10 платформаны шартлатканнар һәм бензин тутырылган 6 цистернаны яндырганнар.

* * *

Түбәндә полиция дивизиясеннән Ленинград фронтында үтерелгән немец лейтенанты Вальтер Геллерның көнлек дәфтәреннән аерым урыннар игълан ителә.:

«29 ноябрь, 42 ел. Сугыш Германия өчен актык көч белән алып барыла торган көрәш төсенә кереп бара... Баштарак без туган илгә кайту өмете белән сугыша идек. Ләкин хәзер инде өенә исән-сау кайтачагына кем өметләнә ала? Хәзер җиңүгә өмет аз, хәзер андый өмет гомумән юктыр инде.

31 декабрь. Хәзер инде без яңа елга нинди булса да өметләр баглый алабызмы? Без, ярсулы һәм ачулы хәлдә, сугышның озакка сузылуы факты алдында торабыз.

21 январь. Дивизия коточкыч югалтуларга дучар ителә. Безнең полктагы офицерлар барысы да диярлек үлеп бетте. Куркыныч бик зур. Җимерелгән подразделениеләрнең кызганыч калдыклары башка частьларга күчерелде, ә калганнары чолганып алынганнар булса кирәк... Әйе, бу, билгеле, бик авыр һәм төзәтергә мөмкин булмаслык кризис».

* * *

Кызыл Армиянең ударлары астында чигенгән чакта немец-фашист кабахәтләр гражданнар халкына карата колак-ишетмәгән ерткычлыклар эшлиләр. Смоленск өлкәсенең Суходол авылында фашист кабахәтләр бер төркем халыкны бер йортка куып кертәннәр. Гитлерчы палачлар хатын-кызларны мыскыл иткәннәр һәм шуннан соң йортны яндырганнар. Үзенең күкрәк баласы белән бергә И. Фомушкина, Евдокия Котова, Екатерина Фрунтова һәм башкалар утта янып үлгәннәр. Барлыгы 24 кеше һәлак булган. Шулар арасында 8 кечкенә бала да булган.

Көнбатыш Франциягә Америка бомбардировщикларының һөҗүме

ЛОНДОН, 14 март. (ТАСС). Англия авиация министрлыгының һәм АКШ ның Европа театрындагы коралды көчләре штабының бергәләп чыгарган белдерүендә әйтелүенчә, 13 нче мартта көндез Американың «Оча торган крепость» бомбардировщиклары Көнбатыш Франциягә һөҗүм ясаганнар. Башлыча Амьендагы сортировка станциясе һәм паровоз депосы бомбага тотылган. Шулай ук Абвил һәм Пуа тимер юл узелларына да бомбалар ташланган. Дошман самолетлары белән ике арада күп кенә һава сугышлары булган. Башлангыч мәгълүматларга караганда, бомбардировщиклар тарафыннан дошман самолетларының берничәсе атып төшерелгән.

Америка бомбардировщикларының операцияләрен Англиянең һәм союздаш илләрнең истребитель эскадрильялары саклап торганнар. Алар дошманның 4 самолетын юк иткәннәр һәм берничәсен сафтан чыгарганнар. Бомбардировщикларның югалтулары булмаган. 6 истребитель үзләренең базаларына кайтмаганнар.

—◇—

Англия авиациясенең Эссенга һөҗүме

ЛОНДОН, 14 март. (ТАСС). Рәсми хәбәрләргә караганда, 12 нче мартта кич белән Англия бомбардировщиклары Льеж янындагы зур машина төзелеше һәм хәрби заводларга һөҗүм ясаганнар. Бомбага тотылган барлык объектларда шартлаулар булган.

13 нче мартта төнлә белән Англия авиациясе Эссенны яңадан бик каты бомбага тоткан. Зенит артиллериясеннән көчле ут ачылуга да карамастан, бомбага тоту уңышлы булган. Башлангыч мәгълүматларга караганда, Крупп заводларына бик зур зарар китерелгән. 23 бомбардировщик үзләренең базаларына кайтмаганнар.

—◇—

Франциядә партизаннар хәрәкәте

ЛОНДОН, 14 март. (ТАСС). «Дейли мейл» газетасының хәбәр итүенә караганда, хәзерге вакытта Франциядә бик күп партизан отрядлары хәрәкәт итә. Отрядларның берсе Югары Савойяда Арв елгасы буен алган. Бу отрядта 500 кеше исәпләнә. Аларның иң зур күпчелеге Германиягә мәҗбүри эшкә җибәрелүдән качып киткән эшчеләр. Отрядның башында берничә француз офицеры тора. 1.000 кешедән торган икенче бер отряд шулай ук Югары Савойяда операцияләр алып бара. Партизаннар пулеметлар белән, револьверлар, винтовкалар белән коралланганнар һәм аларның 75 миллиметрлы берничә пушкалары да бар.

Партизан отрядларының сафлары өзлексез киңәя. Шул уңай белән гитлерчылар Германиягә җибәрелергә билгеләнгән французларга тауларга качарга ирек бирмәс өчен ашыгыч чаралар күрәләр. Барлык станцияләргә һәм юлларга көчле патрульләр куелган.

Шуңа да карамастан, Германиягә мәҗбүри эшкә барудан качкан француз яшьләре Альпының таулы районнарына өзлексез килеп торалар. Күп кенә яшь французлар Альпы районнарындагы тауларда хәрәкәт итүче партизан отрядларына керәләр.

—◇—

ИДЕННЕҢ ВАШИНГТОНГА БАРУЫ

ВАШИНГТОН, 13 март. (ТАСС). Ак Йорт түбәндәге белдерүне игълан итте: «Англиянең чит ил эшләре министры Антони Иден әфәнде, Америка хөкүмәтенең чакыруы буенча, Вашингтонга килде. Аның килүеннән максат—сугыш белән бәйләнгән барлык мәсьәләләр буенча Америка хөкүмәте белән гомуми фикер алышу, сугыш белән бәйләнгән мәсьәләләрне карау буенча берләшкән милләтләр хөкүмәтләре арасында ясалачак киңәшмәгә әзерләнү өчен яхшырак методны тикшерү. Иден әфәнде шулай ук Кушма Штатлар тарафыннан үткәрелә торган гаять зур хәрби тырышлыкларның кайберләре белән турыдан-туры танышырга уйлый».

ИЗЮМ РАЙОНЫНДА

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ, 14 март. (**ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән**). Туктаусыз артиллерия тавышы берничә километрдан ишетелеп тора. Безнең гаскәрләр, үз позицияләренә ныгып урнашып, дошманга каршы каты сугышлар алып баралар, аңа өзлексез контрударлар ясыйлар, аның җанлы көчләрен һәм техникасын юк итәләр.

Гитлерчылар бер участокка танклар һәм мотопехота җибәрделәр. Безнең артиллеристлар дошманны ут белән каршы алдылар. Ике тапкыр орден алган гвардияче өлкән лейтенант Моторинның батареясы берничә минут эчендә немецларның 2 танкысын һәм пехота төялгән 1 автомашинасын сафтан чыгарды. Сержант Макаровның орудие расчетына каршы дошманның 8 танкысы килә иде. Фашистлар часть урнашкан урында паника тудырырга һәм анда бәреп керергә исәп тоттылар. Ләкин артиллеристлар каушап калмадылар. Алар, төз ут белән ике танкны сафтан чыгардылар, ә калганнарын качып китәргә мәҗбүр иттеләр.

Башка участокларда да дошманның атакалары нык торып кире кайтарыла. Безнең артиллеристлар дошманны аеруча зур югалтуларга дучар итәләр. Сугышларның 5 көне эчендә майор Веремеев часте артиллеристлары немецларның 31 танкысын юк иттеләр. Шул ук вакыт эчендә бер частьның артиллеристлары 30 дан артык танкны яндырдылар

Зур югалтуларга да карамастан, дошман үзенең атакаларын туктатмый. Сугышлар бик каты бара һәм бу сугышларда совет сугышчылары үз-үзләрен аямыйча сугышып, батырлык үрнәкләре күрсәтәләр.

Бер урында немец автоматчиклары бер күперне кулга төшерделәр һәм бу күпердән дошман үзенең танкларын һәм мотопехотасын күчерергә уйлады. Бик тизлек белән күперне шартлатырга кирәк иде. Бу бурычны өлкән лейтенант Шайдуров һәм лейтенант Бушманов үз өсләренә алдылар. Алар, автоматчикларның көчле уты астында күпергә шуышып барып, миналар куйдылар. Берничә минуттан күпер юкка чыкты.

И. ЛОПОНОГОВ.

Җаваплы редактор И. УЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре—73—27, типография 36—60.

ПФ 1079 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 424